РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ЮГАРЫ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ»

Г.Г. Зәйнуллин

# *Мөнәҗәтләр, бәетләр һәм тарихи җырлар*

УКУ-УКЫТУ КУЛЛАНМАСЫ

КАЗАН
2014

**УДК 398**
**ББК 82-3**
**З 17**

Ислам диненең тарихын һәм мәдәниятын тирән белүче белгечләрне хәзерләү буенча Федераль максатлы программасы чикләрендә Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Фәнни Советы рекомендациясе буенча басыла

**Рецензентлар:**

филология фэннэре докторы, профессор Хисамова Фэһимэ Миргалим кызы,
филология фэннэре кандидаты, доөент Гыйлемшин Флүр Фоат улы

**Зәйнуллин Г.Г.**

**З 17** **Мөнәҗәтләр, бәетләр һәм тарихи җырлар:** уку-укыту кулланмасы / Г.Г. Зәйнуллин. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2014. – 61 б.

**ISBN 978-5-00019-271-9**

Халкыбыз тарихының фаҗигалы, авыр көннәрендә рухи азык булып хезмәт иткән мөнәҗәт-бәетләребез бүген яңадан өйрәнелә башлады. Тәкъдим ителә торган китап югары уку йортларының музыка, сәнгать факультетларында һәм музыка мәктәпләрендә татар фольклорын өйрәнгәндә кулланма булыр.

**УДК 398**
**ББК 82-3**

**ISBN 978-5-00019-271-9**

**© Зәйнуллин Г.Г., 2014**
**© Казан университеты нәшрияты, 2014**

# ЭЧТӘЛЕК


Моң чишмәсеннән бер йотым ........ 4
**Мөнәҗәтләр** **5**
Йә Рәсүлем! ........ 6
Аллаһ дию-дию ........ 7
Вәйселкарани ........ 8
Мәрхәбә ........ 9
Раббыга мәдхия ........ 9
Гайса көе ........ 11
Укы Коръән илә намаз ........ 12
Касыйдаи шәрифә ........ 13
Тәравих тәсбихе ........ 14
Мөхәммәт пәйгамбәргә мәдхия (Салават әйтү) ........ 17
Хәзрәтләр мөнәҗәте ........ 18
Әҗәлләргә дәвалар юк ........ 20
Әлвидаг ........ 21
Алты бармак ........ 23
Ахирәт көне ........ 23
Аһ дәрига ........ 24
**Бәетләр** **26**
Кыйссаи Авык ........ 27
Бәйте Шәһри Казан ........ 31
Себер киткән егет бәете ........ 33
Үги бала көе ........ 34
Татар мөһаҗире бәете ........ 35
**Тарихи җырлар** **37**
Фаҗигаи Казан ........ 38
Шәһри Кашан ........ 39
Сөембикә китеп бара ........ 41
Тоткын Сөембикә җыруы ........ 42
Сөембикә манарасы (1 шәкел) ........ 43
Сөембикә манарасы (2 шәкел) ........ 44
Хан мәсҗеде (3 шәкел) ........ 45
**Мәхәббәт җыры** **46**
Хан кызы ........ 47
Дәвалау ырымы ........ 48
Кечкенә дә төш кенә ........ 49
Сүзлек ........ 51
Аңлатма һәм искәрмәләр ........ 59

# МОҢ ЧИШМӘСЕННӘН БЕР ЙОТЫМ

Татар халкының бихисап күп мөнәҗәт, мәкам, зарлы еглау-сыктаулары, көйле бәетләре бар. Әмма бу сагыш тулы моң чишмәләренең тавышын ишетүдән без озак еллар мәхрүм булдык. Дини эчтәлеклеләренә бөтенләй «көн» булмады. Гүя безнең халкыбыз аларны белмәгән дә, ишетмәгән дә...

«Мөнәҗәт» сүзе – гарәпчәдән «Аллаһыдан ялвару, ярдәм сорау, зарилык кылу, сыктау» дип тәрҗемә ителә. Фәндә аны «дини тезмә әсәр» дип атыйлар. Бу термин татар мөнәҗәтләренә тулысынча ярашып бетми шикелле. Чөнки татарлар арасында аерым шәхесләрнең фаҗигале язмышлары, сагышлары турында язылган мөнәҗәтләр дә бар. Еглау-сыктау эчтәлекле мөнәҗәт рәвешендә башкарыла торган әсәрләр дә юк түгел.

Халык авыз иҗатының бу жанры безнең бабаларыбызга кайчаннан башлап мәгълүм булгандыр, хәзергә анысы ачыкланмаган. Шунысы бәхәссез, аларда халкыбызның ачы язмышы, фаҗигале үткәне чагыла. Мөнәҗәтләр моңы музыка сәнгатебезгә дә тәэсир итми калмаган. Әдәбиятыбыз сәхифәләрендә дә мөнәҗәтләр, аларны башкаручылар турында язылган.

Мөнәҗәт-мәкамнәрне ир-атлар да, хатын-кызлар да башкара. Ләкин мөселманнарда хатын-кыз җенесе аларны беркайчан да ир-ат булган урында башкармаган.

Мөселман халыкларында мөнәҗәтләрне музыкага ияреп башкару гадәткә кергән. Кайбер илләрдә илаһи эчтәлекле мөнәҗәтләр, мәкамнәр башкаручы оркестрлар, осталар бар. Төрки халыклардан азәрбәйҗан, төрек, үзбәк, төрекмәннәр исә мөнәҗәт-мәкамнәрне кыллы уен коралына кушылып әйтәләр.

Халкыбызның моң чишмәсеннән бер йотымын гына булса да тәшкил иткән бу җыентыкка егерме сигез мөнәҗәт, тарихи җыр, бәет, йола җыры тупланды. Аларның күпчелеге нотага салып тәкъдим ителә.

Җыентыкка кергән бәетләр, мөнәҗәтләр, җырлар татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә язып алынды. Әмма аларның зур өлешен Татарстанда, әнием Маһибәдәр Хәлиулла кызы һәм әтием Габделхак Зәйнулла углыннан язып алган идек. Көйләнеше дә алар башкарган төсмерләр белән бирелде.

Йа Рабби! Халкыбызның иреге, динебезнең пакълеге, сафлыгы өчен шаһит киткән изге затларыбызның караңгы гүрләрен, рухларын якты кылып, авыр туфракларын җиңел итсәң иде!

Ошбу хезмәтебез ата-бабаларыбыз вә барлык туганнарыбыз рухына дога булып ирешсә иде! Амин!

Җәмил Зәйнуллин

# *МӨНӘҖӘТЛӘР*

## ЙӘ РӘСҮЛЕМ![*]

Йә рәсүлем Мөхәммәт, кыйлдың галәмгә рәхәт,
Чиктең дөньяда зәхмәт, өммәтең өчен мостафа.
    Сальяллаһи галәйкә –
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Аллаһүммә бу галәмне синең өчен яратты;
Әүвәлгедән ахырынача синең исемең таратты.
    Сальяллаһи галәйкә –
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Әүвәлге пәйгамбәрләр һәммәсе белде сине!
Сән идең хәтемән-нәбийә, барчасы өммәт сиңа.
    Сальяллаһи галәйкә –
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Китабың булды Коръән, бөтен галәмгә солтан!
Син Мөхәммәт мостафа, безгә шәфәгатьче син.
    Әй Мөхәммәт мостафа, –
    Сальяллаһи галәйкә,
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Син Аллаһының хабибе, гөнаһларның табибе,
Һәркем сине йад итте, әй Мөхәммәт мостафа!
    Сальяллаһи галәйкә,
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Мәккә шәһәрендә тудың, атаң иде Габдулла,
Анаң иде Әминә, йә Мөхәммәт мостафа!
    Сальяллаһи галәйкә,
    Безгә шәфәгатьче син,
    Йә Мөхәммәт мостафа!

Атаң-анаң вафаты сине ятим калдырды,
Сәне Аллаһ үстерде,
        йә Мөхәммәт мостафа...
Сальяллаһи галәйкә,
        йә Мөхәммәт мостафа!
Безгә шәфәгатьче син,
        йә Мөхәммәт мостафа!

[*] Сүзләргә аңлатмалар һәм искәрмәләр китапның ахырында бирелде.




## АЛЛАҺ ДИЮ-ДИЮ

Айдан яктыдыр йөзләре,
Шикәрдән датлы сүзләре,
Җәннәттә хури кызлары
Гизәр Аллаһ дию-дию...

Салынып тути ботаклары,
Коръән укыр һәм делләре,
Җәннәт багының гөлләре
Исәр Аллаһ дию-дию...

Тәмле йийүб, тәмле эчәр,
Идрис нәби хөллә кисәр,
Мәликәләр рәхмәт сачар
Сөбханаллаһ дию-дию...



# ВӘЙСЕЛКАРАНИ

Гасасы вар иде аның илкендә,
Камәре вар иде аның билендә,
Аллаһының зикре датлы телендә.
    Йәмән илләрендә вәйселкарани –
    Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Пәйгамбәр мәсҗедтән өенә килде –
Гайшәдән сорады: «Өйгә кем килде?»
Дустының килгәне турында белде...
    Йәмән илләрендә вәйселкарани –
    Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Һәр сәхәр вакытында бу иде касды,
Арпадин икмәге идеке ашы,
Акарды күзендән мөбарәк яше.
    Йәмән илләрендә вәйселкарани –
    Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Хиркасе вар иде дәүә йонындан,
Гасасы вар иде хөрмә талыннан.
Һич хата чыкмас иде датлы телендән.
    Йәмән илләрендә вәйселкарани –
    Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.



## МӘРХӘБӘ

Мәрхәбә, йә нуре гайни,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!
Мәрхәбә җәддүл Хөсәйни,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!

Күн шәфигый, йа хабиби,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!
Йәүмә хәшри вәҗтимагый,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!

Раббәна сальли галә мән,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!
Хәлли фи хәйрил бәкаи,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!

Вә галә әлин, вә сахбин,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!
Мә сагә лиллаһи сагә,
мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә!




## РАББЫГА МӘДХИЯ

Хәмде әйтәм сиңа, Раббым,
шөкер кыйлдың безне мөэмин,
Яраттың дине исламнан,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Хыйфыз итеп күңелебезне
көфер-шәрик карасыннан

Иман нуры илә нурладың,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Мөкатдәс мөбарәк Китабың
безгә җибәргүчедерсең,
Вә күрсәтдең ачык юлны,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Рәсүлебез Мөхәммәтне
җибәрдең җөмләдән ахыр,
Вә иттең барысыннан әфзаль,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Хәдисе Коръәнең илән
гамәл итүче иман әһле,
Рәхәт яшәр бу дөнъяда,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Хосусан ахирәт көнне
котылыр мәңге газаптан,
Ирешер мәңге рәхәткә,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Шушы зур нигъмәтең өчен
ничек сиңа шөкер кыйлмыйк,
Бурычлы без шөкергә һәм
хәмде әйтәм сиңа йаһу.

Шөкердә без делебездә,
дәхи фигыль гамәлебездә,
Кабул ит, нәкъсы улса да,
хәмде әйтәм сиңа йаһу.



# ГАЙСА КӨЕ

Кадийр кодрәтен тыңлаб, бер сүзем йад кылдийа,
Гизләп аны тотсам, булмас мәүлем гыйта-бирдийа;
Мәрьям углы ул Гайса хасс кол ирде мәүлегә,
Мәүлем аны агырлап, Инҗил гыйта бирдийа.

Бу дөньяны бакмаган малга күңел бу микән?
Ил эчендә тормаган Гайса сәүче ирдийа...
Талак бирде дөньяга, кадәм орды гакбегә -
Тагат кыйлды мәүлегә, төнлә уйаг тордыйа.

Мәрьям ирде анасы, һич юк ирде атасы...
Әнбияләр иясе йилдин тугмыш ирдийа;
Кайу әйүгә ул керсә, әйүдә күзсезне күрсә,
Торуб догалар кыйлса, күзле улыр улия!

Гайса әйтүр: Әй ана! Бер пәнд итәлүм сәңа...
Ул пәндемне сән аңла, бер сүзем йад кылдийа.
Ана-углы кубалум, келим тунын кийәлүм;
Бу дөньяны куйалум, тагат вакты булдыйа.

Мәрьям әйтүр: Әй углым, күрер күзем, колагым,
Киләседер бу үлем, йимеш йитдең, тидийа;
Ана-углы кубдылар, келим тунын киделәр.
Бу дөньяны куйдылар, ахирәткә йандийа.



# УКЫ КОРЪӘН
# ИЛӘ НАМАЗ

Газраил кателгәнче,
Әҗәл угы кадалганчы,
Билең-телең тотылганчы,
Укы Коръән илә намаз.

Сузып кабыкка салганчы,
Илтеп гүрләргә куйганчы,
Җавапларыңны биргәнче,
Укы Коръән илә намаз.

Укы иртән намазыңны,
Кошлар тыңлар авазыңны;
Ышанма угыл-кызыңа,
Укы Коръән илә намаз.

Булырсың әһлеңнән ерак...
Киярсең җиңсез әфрак;
Өсте такта, төбе туфрак,
Шул өеңне уйла, мескен.

Шайтан сиңа сөялмәсен,
Тезгенеңне бәйләмәсен,
Хакка дошман әйләмәсен...
Укы Коръән или намаз.



## КАСЫЙДӘИ ШӘРИФӘ

Вөҗүдем җөмләсе гыйсъян,
Нә миндә хәйр, нә ихсан...
Бу халәт берлән йә гыйфран.

Халаекның кеме заһид,
Кеме галим, кеме габид,
Вә кеме суфи, кеме мөршид?!

Кеме гыйльмен гайан кыйлгай,
Кеме зөһдин бәйан кыйлгай?!
Гамәллекләр әман булгай.

Әгәр фазлың берлән сөйүрсәң,
Котылгаймын гафу кыйлсаң,
Вә кәррә гадьлең белән сөйүрсәң.

Тәнемдин туным суйганда,
Җаным ләхеткә куйганда,
Башымдин суны койганда.

Ата-ана башы берлән,
Углыгыз күз яше берлән,
Булыр башлыг башы берлән.

Ушал көн, йә Рәсүлүллаһ,
Сәвенерсәң сәңа валлаһ,
Шәфәгать кыйлмасаң нәгяһ

Алайы Шәмсетдин үзе китде,
Камуг йаранлары йанды,
Гөнаһындин багышланды...

Ашыкмыйча, ирекчән




1) Мөнәҗәтнең 1-3,5-7 юллары шушы көйгә укыла.
2) Мөнәҗәтнең 4,8 юллары шушы көйгә укыла.

## ТӘРАВИХ ТӘСБИХЕ

Тәравих – Рамазан аенда һәр көн кичен укыла торган егерме рәкәгать намаз. Тәравих вакытында тәсбих, йә тәһлил әйтеп, яки әйтелгәнне тыңлап утыру тиешле. Татарлар арасында тәравих вакытында тәсбих көйләп әйтелгән.

Сөбханә зил-мөлки вәл-мәләкүт!
Сөбханә зил-гыйззәти вәл-газамати
вәл-кодрәти,
Вәл-кибрияи вәл-җәбәрүт!

Сөбханәл-мәликел хәйел-ләзи лә йәмүт!
Сөббухүн, коддүсүн, раббүл-мәләикәти вәр-рух!
Лә-иляһе илләл-лаһе нәстәгъфируллаһ!
Нәсъәлүкәл-җәннәтә вә нәгузе бикә минән-нари!

*Мәгънәсе:* Җирдәге һәм күктәге мәхлукатьнең хуҗасы Аллаһ Тәгаләне ихлас күңелем белән яратамын! Гыйззәт, кодрәт һәм бөеклек иясе Аллаһыны ихлас күңелем белән яратамын! Бөтен галәмнең патшасы һәм һичкайчан үлми торган тере булган зат – Аллаһ Тәгаләгә ихлас күңелем белән инанам! Бер генә кимчелеге булмаган саф, пакъ һәм изге зат Аллаһ Тәгалә барлык фәрештәләрнең дә, Җәбраил фәрештәнең дә Раббысы ул! Аллаһ Тәгаләдән башка илаһи көч тә, тәңре дә юк! Без аңардан булган гөнаһларыбызны ярлыкавын сорыйбыз! Әй Раббым! Безне җәннәтле итеп, тәмуг утларыннан йолып, саклап калсаң иде!

1 шәкел



## ТӘРАВИХ НАМАЗЛАРЫ ТӘМАМ БУЛЫП, БИШЕНЧЕ ТӘСБИХ ӘЙТЕЛГӘННӘН СОҢ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Аллаһүммә сальли галә
Мухаммәдин вә галә әли Мухаммәд вә сәллим.
Аллаһүммә зәйиннә би-зийнәтел иймәни!
Вә шәррифнә би-шәрәфәтел һидайә вәл-гыйрфани!
Вәкримнә би-сыями шәһри рамаданә,
вәрзукнәл-җәннәтел-гуфранә!
Вә тәкаббәл миннә тәравиханә йә сөбханү!
Вәстәҗиб догаәнә йә ханнанү!
Би-фазликә вуҗудикә йә мәннану!
Би-рәхмәтикә йә-әрхамәр-рәхимийн!

*Мәгънәсе:* Йа Рабби! Мөхәммәт галәйһис-сәламга һәм аның өе, гаиләсенә рәхмәт вә сәлам ирештер! Йа Рабби! Безне иман зиннәтләре белән зиннәтләп, рамазан аеның рузасы белән хөрмәтләсәң иде! Безгә җәннәтеңнән урын биреп, булган гөнаһларыбызны ярлыкасаң иде!

Әй шәфкать ирештерүче, берәүдән дә сорамыйча боеручы Аллаһыбыз! Үз яхшылыкларың һәм бөеклегең белән догаларыбызны кабул кыл! Йа Рабби! Бар нәрсә дә синең шәфкатең, миһербанлыгың, рәхмәтең белән булыр!

2 шәкел



# МӨХӘММӘТ ПӘЙГАМБӘРГӘ МӘДХИЯ
# (САЛАВАТ ӘЙТҮ)

## *1 шәкел*

Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә, йә Рәсүлүллаһ!
Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә, йә хәбибаллаһ!
Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә, йә нәбиаллаһ!
Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә,
йә хәйрә халикыйллаһ!

Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә,
йә нуре гаршеллаһ!
Әссаләтү, вәссәләмү галәйкә,
йә сәхибә кабә куәтәйн!
Әссаләтү, вәссәләмү галә әшрәфел мөрсәләйн!
Галә әлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн!
Вәлхәмделиллаһи раббелгаләмийн!

## *2 шәкел*

Әссаләвәт, вәссәләмү галәйкә,
йә шәфигаль өммәт!
Әссаләвәт, вәссәләмү галәйкә,
йә кәшифел гоммәт!
Әшрәфәл бәдрү галәйна
фә әхтәфәт минһүл будур!
Мислә хөсникә мә рәәйнә катту,
йә вәҗәһәс-сорур!

Әнтә шәмсү, әнтә бәдрүн,
әнтә нурүн, фәүка нур!
Әнтә иксирүн вә галийүн,
әнтә мисбахүс-содур!
Йә хабиби, йә Мөхәммәд,
йә горвасәл хафикайн!
Йә муаййәд, йә муммәҗҗәд,
йә имамү кыйблатәйн!

Фи мәганийкәл әнгамү кад
тәбәддәт хайрийнә!
Әнтә лир-рүсүли хитамүн,
әнтә лил-мәүлә шәкүрү!
Габдүкәл мискину йәржү
фазләкәл җәмал гафирү!

## САЛАВАТ ӘЙТҮНЕҢ СОҢЫНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

Илә рухи сәйидинә, вә нәбийинә, вә мәүләнү Мөхәммәди-әлмостафа сальляллаһу галәйһи вә сәлләм, вә галә әлиһи, вә әсхабиһи, вә әһли бәйтиһил кирам! Лилләһил фәтихәт дәгавәйһүм фиһа сөбханә. Аллаһуммә вә тәхийәтүһүм фийһа сәлам! Вә ахирү дәгавәйһүм әнилхәмдү лилләһ раббелгаләмийн. Аллаһуммә сальли галә сәйидинә вә нәбийинә вә мәүләйнә Мөхәммәд!

*Мәгънәсе:* Җитәкчебез вә пәйгамбәребез, олы зат, пакълек һәм сафлык иясе Мөхәммәт рухына багышладым (багышлыйм). Аллаһ аңарга, якыннарына, сәхабәләренә (иярченнәренә, көрәштәшләренә) һәм аның бөек йортының әһелләренә изге теләкләребезне ирештерсен иде! Аларның кылган гамәлләрен олугласын иде! Йа Раббым! Аларга мактау сәламнәрен ирештерсәң иде! Аларның соңгы догаларына, игелекле эшләренә олылау сүзләре дә ирешсен иде!

Йа Рабби! Безнең җитәкчебез – пәйгамбәребез Мөхәммәткә иң олы мактау һәм теләкләребезне, сәламнәребезне ирештерсәң иде!

## ХӘЗРӘТЛӘР МӨНӘҖӘТЕ

Бисмилләһ дип багышладым бер мөнәҗәт,
Аллаһ исеме һәр бәндәгә булыр хаҗәт.
Ул Мөхәммәт мостафага күп салават,
Бу салават һәр бәндәгә сөннәт имди.

Аһ дәрига! Хубларига еглап үтте,
Анасыннан тугды ирсә, матәм тотты.
Ул газизләр барчасына сабыр итте,
Безләргә дә сабыр-җәмил биргел имди.

Атабыз Адәм җәннәт эчрә гашрәт күрде,
Бу дөньяга иңгәч, бик күп хәсрәт чикте.
Аллаһ аның тәүбәсене кабул кыйлды,
Инша Аллаһ җәннәт насыйп кыйлыр имди.

Дөньяда күп җәфа күрде ул Нух нәби,
Икенче ата диерләр аны безгә,
Сау-сәламәт саклады судан аны,
Безләргә дә фәүзе-нәҗат кыйлгын имди.

Юныс нәби дәрьяга үзен атты,
Дәрьяга төшү берлән балык йотты.
Балык эчрә кырык көн тәсбих әйтте,
Безләргә дә истикамәт биргел имди.

Йосыф өчен күп еглады Ягъкуб нәби,
Корьәндә һәм китапларда сөйләнә аның хәле.
Ахры бер көн кавыштырды халык аны,
Безләргә дә кавышу насыйп кыйгыл имди.

Йосыф сыйддикъ дөньяда күп җәфа күрде,
Җәфадан соң Мисыр үзрә матәм тотты.
Ахыр анда бик күп рәхәт гомер сөрде,
Безләргә дә фәүзе-нәҗат биргел имди.

Әюб нәби дәхи күп рәнҗү күрде,
Һәм янә күп бәлага дучар булды.
Ул газизләр, барча сәнә сабыр кыйлды,
Безләргә дә сабыр-җәмил биргел имди.

Унсигез мең галим фәхре Рәсүлүллаһ –
Бу дөньяда ул да күрде бик күп җәфа.
Салават әйтмәк – җанга ләззәт, телгә шифа,
Шәфәгатең безгә насыйп кыйгыл имди.

Йәзид кауме ул Хәсәнгә агу бирде,
Хөсәенне Кәрбәләдә шәһит итте.
Ул газизләр барчасына сабыр итте,
Безләргә дә сабыр-җәмил биргел имди.

Сәхабәләр, чаһар йарлар – барысы үтте,
Һәр барчасы кайгы-михнәт күреп китте.
Күргән хәлен барчасы да язып китте,
Бу хәлләрдән без дә гыйбрәт алыйк имди.




## ӘҖӘЛЛӘРГӘ ДӘВАЛАР ЮК

Оча торган кошлар кеби
һаваларда йөрсәң иде.
Кереп җәннәт сараена дидарыңны күрсәң иде.

Барыр җирем – кара туфрак,
ятар җирем – кызыл балчык,
Кыямәт көне булганда
йөземне кыйл, Раббым, ачык.

Әҗәлләргә дәвалар юк,
әҗәлләргә гозерләр юк,
Бакый иман белән үтсәк,
булыр эшләребез бөек.
Ата-аналарыбыздин аерадыр ачы үлем,
Ходаем рәхмәтен салса,
якты булыр бәнем гүрем.

Кәүсәр дигән елгалардин суларыңны эчерсәнә,
Яшеннәр яшьнәгән кеби сиратындин кичерсәнә.

Бу дөнья да бездән калыр,
кара туфрак чорнап алыр,
Кара туфрак астында кол,
күзен ачса, хәйран калыр.
Бер ходаем сабыр әйлә,
теләгебезне кабул әйлә,
Фирдәвеси җәннәтеңне барчабызга насыйп әйлә.




## ӘЛВИДАГ

Әлвидагу, әлвидагу,
Шәһри рәхмәт, әлвидаг!
Лә иляһе илләллаһи,
Лә иляһе илләллаһ!

Кәлер көндә, җир вә күктә
Җөмлә мәләик сәүнешәр.
Кәтде көндә, аглашубән
Чуглашырлар, әлвидаг!

Нурың илә зәйн улыбдыр –
Җөмлә мәсҗедләр тәмам.
Зикре тәсбих, вә тәравих
Кәтди бездин, әлвидаг!

Коръән инде ошбу айда,
Аять-аять бәйинат!
Хасәнәтләр тәшриф улыб,
Җөмләдерлү сәйедат!

Фәрештәләр саф-саф улыб,
Җир йөзенә иңәрләр!
Алларындин нурдин табак,
Мөэминәләр сонарлар!

Хак тәгалә сезне-безне
Гофран өчен әйләмеш.
Сән Мөхәммәт өммәтирсәң –
Сәңа ихсан әйләмеш!

Әлвидагу, әлвидагу,
Шәһри рәхмәт, әлвидаг!
Лә иляһе илләллаһи,
Лә иляһе илләллаһ!



## АЛТЫ БАРМАК

Багышладым гөнаһы пәс дога кыйл,
Нә истәрсәң, уийрам хаҗәт рәүа бел.

Диде Җәбраил аңа: Тор, авыру, пәс,
Кә рәфыг улды хиҗаб нуре кодәс.

Ачылды күкләрең капусы җөмлә,
Сачылды җәннәтең сачусы җөмлә.

Канәдин орды, җирдән чыкты чишмә,
Күркесе әтайиб иде җана чишмә.

Иреште сөйләдеке рәхмәте аңа,
Киерде хөлләләр җәннәттә аңа.




## АХИРӘТ КӨНЕ

Ошбу айларда Рәсүл һиммәте,
Булсакчы безләр аның өммәте,
Иман нурлары булсын безләрдә,
Рәсүл шәфәгать кыйлсын безләргә.
Кыямәт көне – мондый авыр көн,
Безләргә шәфкать, Раббым, үзең кыйл;
Ярлыкыйм дигән вәгъдәң бар синең,
Шәфәгать кыйлып, хабибем диген.
Оҗмахны бизәр, юлларны төзәр,
Өммәтләр килә, дип, Рәсүл көтәр.
Тар каберләргә кереп ятарбыз,
Аллаһ каршына ничек барырбыз?

Гөнаһы кыйлсак, гайбәт сөйләсәк,
Бер хода бездән тәмам бизәчәк.
Дин кардәшләрем, уйлап карыйк без:
Дөньяда чакта аны таныйк без.
Газраил килер, җаннарны алыр,
Иманлы булсак, рәхмәтен салыр.
Ирекле кыйлма Иблис мәлгуньне,
Рәхимсез кыйлма Мөнкир, Нәкирне.




## АҺ ДӘРИГА

Аһ, дәрига, гомер үтте – беләлмадым,
Ихлас белән хакка коллык кылалмадым.
Ахры бер көн хәзрәтемә баралмадым,
Инде белдем: хәсрәт миңа төште, дуслар.

Аһ, дәрига, гомер үтте, тоймый калдым,
Бу дөньяда малны җыеп кулыма алдым,
Дөнья куып дин эшене артка салдым, -
Бу дөньяны ярты акчага саткым килер.

Әле мин яшь торырмын дип әйтүр идем,
Һәрнә хасыйл булса, аз дип торыр идем,
Төрле-төрле дәгъвалы эшләр кыйлыр идем,
Инде белдем: мин әйткәннәр булмас икән!

«Дөнья – минем милкем» дигән солтаннарга,
Залим булып кеше малын җыйганнарга,
Гыйш-гыйшерәт берлән мәшгуль булганнарга
Үлем килсә, бере вафа кыйлмас ирмеш.

Гакыл ирсәң, гүрестаннан гыйбрәт алгыл,
Мин һәм шунда барырмын мин еглап йөргел,
Мәүте каблә әт-тәмугка гамәл кыйлгыл!
Бу җирләрдә үлмәс борын дога кылыйк!

Руза тотып, намаз укып тәүбә кыйлгыл,
Хәзрәт булса, аның сари йөри торгыл;
Чын дәрвишләр тагатларын пинһан кыйлур,
Кәси күрсен өчен гамәл кыйлмаң, дуслар.

Дәрвиш булсаң, тагат кыйлгыл, кыйлма рия,
Һәр төштә намаз кыйлсаң, Аллаһ күрә,
Ялган дәрвиш кайда барса, ризкы һава –
Гадел патша тагатларын гыйсъян кыйлур.

# БӘЕТЛӘР

# КЫЙССАИ АВЫК

Кяфир биге авык аулаб килүр ирде,
Сәвеклүк Рәсүл юл үзрә торур ирде,
Кырык кяфир терек авык тотмыш ирде,
Мөхәммәткә авык разын әйтүр имди.

Рәсүл торуб кяфирләргә каршы килде,
Кырык кяфир Мөхәммәткә сәлам кыйлды.
Кырык кяфирнең сәламен Мөхәммәт алды,
Агзын ачуб Рәсүл авыкны теләр имди.

Кяфир әйтүр: Кырык ир берлә ау ауласы,
Бу көн килүб тагдин-тагга аша йөрүр.
Кырык ир берлә ау аулаб ялгыз киек тотсам,
Нәтәк биргәймен бу авыкны, тийүр имди.

Рәсүл әйтүр: Бу авыкны миңа сатгыл,
Алтын-көмеш кирәк булса, миндән алгыл;
Ошбу зәгыйфь авыкны миңа биргел.
Кяфир торуб мондаг җавап бирүр имди.

Кяфир әйтүр: Миндин нә өчүн теләйүрсән?
Канын алуб җадуалыклар әйләйүрсән,
Нә монча моның өчүн кателләнүрсән? –
Тугры сүзле моны сиңа боерам имди.

Рәсүл әйтүр: Бу авыкны үлтермәсмән,
Канын алуб җадуаләтләр әйләмәсмән.
Бу авыкны үзем өчен теләмәсмән,
Авык миңа кәндү разын әйтүр имди.

Кяфир әйтүр: Миңа нә өчүн разын әйтмәс?
Кырык ир моның өнүн һич ишетмәс?
Гарәп халкы ялган тәкый сүз сүзләмәс!
Мөхәммәтне ялганчы тиб сүкәрләр имди.

Рәсүл әйтүр: Ошбу авык миңа сүзләр,
Күңлендәге разы булса, миңа ачар.
Авык әйтүр: Минем кечүк балаларым бар,
Үксез калды балаларым, әйтүр имди.

Авык әйтүр: Көн дә тагга чыкар ирсәм,
Төрлүк-төрлүк сачәкләрне утлар ирдем;
Кичә килүб балаларым имезүр ирдем,
Бу көн килүб бу бәлагә төштем имди.

Рәсүл әйтүр: Кызганырмын бу авыкны,
Тагда калмыш өч кечүчүк угланнары.
Аның өчүн ялварурмән сез кяфирләргә,
Рәхим кыйлуб мин шәфәгать кыйлам имди.

Кяфир әйтүр: Кем рәхименә килүр ирсә,
Ошбу авык баек сиңа сүзләр ирсә –
Зарын ачуб сәндин хаҗәт теләр ирсә,
Син буйуңны йөккә бу авыкка куйгыл имди.

Без тораек, ошбу авык әйүнә китсен,
Балаларын имезүбән кайра килсүн.
Килмәз ирсә, ошбу сүзләр нитәк булсын,
Кырык ир берлә сиңа икърар кыйлам имди.

Авык баруб килерүн үзен күрәм,
Пәйгамбәрлек сәндин ирмеш, баек беләм.
Килмәз ирсә, кылыч берлә башың кисәм,
Рәсүл берлә буйлә вәгъдә кыйлур имди.

Рәсүл әйтүр: Бу авыкка мин бараен,
Йире кайда, йорты кайда, мин сораен.
Качан баруб килерүн мин беләйүн,
Соңра мин буйум йөккә бу авыкка куям имди.

Кяфир әйтүр: Йә Мөхәммәт, моны аңла,
Балаларын имди сорагыл бу авыкка,
Кичәгә тикле ултургаймыз ошбу йирдә,
Мәлгунь кяфир катигъ хаҗәт кыйлур имди.

Фасыйх делен ачуйан авык сүзләр,
Авыкның сүзләдекен Рәсүл аңлар,
Бу икесе сүзләдекен кяфир тыңлар,
Авык анда килүб вәгъдә бирүр имди.

Күзен тикүб авык имди күккә бакар,
Күккә бакуб күләгәсен мондаг күрәр,
Кайра бакуб Рәсүл таба мондаг сүзләр,
Раст икендегә тикрү кайтуб киләм имди.

Тизген баруб балаларым мәңзен күрәм,
Күксүмдәге үз сөтемне бер имезәм,
Андин кайра сиңа баруб тизкен киләм.
Рәсүл әйтүр: Ушал ийшә танук булдым имди.

Атдаен төшүб бераз монда ултураек,
Бу авыкны кидешдин коткарайук,
Качан килүр ошбу авык, без менәйүк,
Кяфир төшүб, кылыч тартуб торур имди.

Әйтүр: Бу көн без тик ирне алдайурсән,
Офтанмайун мондаг ялган сүзләйүрсән,
Илкүмездән бу киекне коткарурсән,
Киек безгә кәндү качан килүр имди.

Торуб-торуб бу кяфирләр күккә бакар,
Көн күләгәсе ике пучук булмыш күрәр,
Моны күрүб кяфирләрнең эче пошар,
Түкәл кяфир кылыч тартып торур имди.

Кяфир әйтүр: Торгыл имди, йә Мөхәммәт,
намаз кыйлгыл,
Намаз кыйлуб, күләгәне торуб күргел,
Йә Мөхәммәт, җадуалыкдин тәүбә кыйлгыл,
Түкәл кяфир кылыч тартып торур имди.

Андин торуб Рәсүлүллаһ күккә бакар,
Күккә бакуб намаз вакты булмыш күрәр,
Андин торуб ике рәкәгать намаз үтәр,
Авык аңа тикрү килүр имди.

Ике рәкәгатьтә әт-тәхийәткә улторур иде,
Ул Җәлилдин Җәбраилгә фәрман булды,
Ул куакны авык берлә алгыл тиде,
Миндин сәлам Мөхәммәткә әйтгел имди.

Ул сәгать Җәбраил хадыр булды,
Ул авыкны үзе берлә алуб килде.
Килүб Рәсүл өнүндә торды,
Рәсүлнең йөзен күрүб еглар имди.

Авык әйтүр: Оятлыг булдым, хата кыйлдым,
Раст икенде намазына киләм тидүм,
Бу кяфирләр тозак кормыш, аңа төшдүм,
Мәндин дәкүл бу кичекмәклек, тийүр имди.

Моны күрүб түкәл кяфир табынышдылар,
Андин торуб Шам халкы тәүәккәл кылдылар.
Моны күрүб ун мең яһүд мөселман булды,
Түкәл кяфир шәһадәтне килтерүр имди.



## БӘЙТЕ ШӘҺРИ КАЗАН

Тарихы йите йөздә кәлде Тимер Болгарга –
Габдулла ханның кулындин
Болгар шәһәрен алдыя.
Ул бөлекнең соңында, Казан суы буенда,
Ике углы кәлүбән Казан шәһәрен салдыя...

Ике йөз алтмыш ике ел Казан мөселман кулында,
Ахыры-бары соңында кяфир урыс алдыя.
Газилары күп иде, кямилләре чук иде,
Галимнәре күп иде, замане Ядкәр ирдийа.

Бу җиһан мөнәүвәр иде, җәүер-җәфа юк иде,
Мөрид-мөршид күп иде, заманы хуб ирдийа,
Галимнәре дуст иде, мөршидләре хас иде,
Барча дошман пәст иде, замане Ядкәр ирдийа.

Ядкәр ханның бер кызы калды тугыз яшендә, –
Халык ишле эшендә, күп гакыллы ирдийа.
Тукыз йөз илле йитедә Ядкәр китте дөньядин, –
Атасының урынына хан булырсың, тидийа.

Син мүәннәс дәгүлмүсән, ханга лаек дәгүлмүсән,
Монча ирләр барында хан булмасмын, тидийа.
Ошбу сүздән гыйбрәт алды,
бу дөньяны юкка салды,
Атасының соңында үз җанын үзе алдыя.

Нәселендә бер ир бар ирде, аның исеме Шигали,
Шифаларга йар иде, тоткын булмыш ирдийа.
Күп халаек бардылар, күп мал биреп алдылар,
Ошбу шәһри Казанга, хан кылдылар ирдийа.

Шәһри Казан эчендә Шигали һәм хан булды,
Дөнья дигән сарайга җәүер-җәфа тулдыя...
Үз-үзене белмәс, күзе һәм малга туймас,
Кяфир-урыстан мал алып, дарыга су койдыя.

Кяфир-урыс ишәйде, Шигалигә кушылды,
Шигали хандин Иван-урыс Казан шәһәрен алдыя.
Кяфир-урыс зур булды,
мөэмин-мөселман хур булды,
Ничә вәли, ничә газиз шәһадәтләр табдыя.

Кяфир-урыс хәбәрдар ирде,
мөселманнар бихәбәр ирде,
Шәһәре Казанның янында
орыш-тукыш булдыя.
Ул орышдин булмады, Казан шәһәрен алмады, –
Ошбу Зөя тагында кяфир кала салдыя.

Мөселманнар күрделәр, сорап-эзләп белделәр, –
Ошбу безем йиремездер, кандин кәлдең, тидийа.
Кайдин кяфир кәлибсән, монда мәкам кылыбсән?
Кемдин рөхсәт алыбсән? – диюбән җиһад кылдыя.

Бар ирде бер мәрди-хода, исеме иде аның Чура
Күп кяфирне кырмага хода мәдад бирдийа.
Бар ирде бер ир үлмәс, исемен аның кемсә белмәс,
Шәһре Казанга кәлгүнчә кемсә күрмәс ирдийа.

Үлмәс белән Әбүлгаликъ
йары ирде Җаббар халикъ,
Мөэминнәрнең үчене барыб алыр ирдийа...
Тиделәр аңа: Йә Чура, ирерсән мәрди-хода!
Аллаһының хикмәтендәдер чарә,
бездән урыска бәддога.

Килеп йитде Чура батыр,
динсез кяфир чадырда ятыр,
Чадыр эченә керүбән, башын кисеп алдыя.
Ултырыб иде ашына, ашы йитде башына,
Ашы алдыннан кәтгүнчә, башы төште ашына.

Гаклы юкдыр башында, күп халкы бар каршында;
Ник боермады бер башына –
                    уструг торың каршымда.
Кисде аның башыны, агызды һәм каныны,
Ул кяфирнең җаныны – җәһәннәмгә бирдия.

Тукыз йөз илле тукызда,
                    сычкан елы иде анда, –
Гакрәбнең икенче көнендә кяфир-урыс алдыя.




## СЕБЕР КИТКӘН ЕГЕТ БӘЕТЕ

Ташаяктан сатып алдым
                    җыермалы ал читек, һай!
Моңайма, күңелем; сызланып,
                    безләрне ятим итеп, һай –
Себерләргә озаттылар,
                    кулларым ла богаулы,
Мөселманның бу җирләрдә
                    гомерләре санаулы.

Биек тауның башларында
                    бер башакта бер богдай, һай!
Бу кадәрле әрнүле итеп
                    ник яраткан бер ходай?

Киң дөнья тар булды бәңа,
күңелләрем сагышлы,
Төнгә керсәм йоклый алмыйм, –
төште кемнең каргышы?

Безгә биргән ашларының ярмасы юк,
бик сыек, һай!
Еглыйм дисәм еглый алмыйм,
күңелләрем бик боек.
Саесканнар оялаган
зинданыбыз башына,
Тагын ниләр төшәр икән
безнең татар башына?




## ҮГИ БАЛА КӨЕ

Өйдән чыгып киткән чакта,
Ашадым тары өйрәсен.
Фингә килеп картаерга
Ходай язган күрәсең.
Өйдән чыгып киткән чакта,
Атларыбыз тук иде.
Финдә гомер үтәр диеп
Уйлаганым юк иде.

Өйдән чыгып киткән чакта,
Төшеп калды тезгенем.
Күрешкәндә еглап калды
Ике сеңелем, бер энем.

Өйдән чыгып киткән чакта,
Ишекләрне япмадым.
Утыз сәнә Финдә торып,
Бер көн рәхәт тапмадым.




## ТАТАР МӨҺАҖИРЕ БӘЕТЕ

Идел буен киң диделәр,
Тар икәнен сиздек без.
Мәҗбүр булдык таралырга,
Чәчелдек тә сибелдек.

Илебездән сөрелгәчтән,
Күп рәнҗүләрне күрдек.
Таралыштык дөнья буйлап,
Каңгырашып казлар кебек.

Казак ягы, Төрекстанны
Эссе диеп сөенештек.
Мөгамлимлеккә керештек
Кинәнешеп, сөенешеп.

Җаек ягы, Сибер ягы –
Урманлык та тигезлектер.
Чәчелдек тә сибелдек без,
Монда җәбер бик күптер.

Мәгърифәт орлыгын чәчтек
Төрекстан, Сибер, Кытайда.
Мәчет, мәдрәсәләр салды
Татар углы япунда да.

Рәхмәт сүзен әйтсәләр дә,
Мескеннәрдән саналдык без.
Кыргый халык уллары дип,
Һәр көн саен каргалдык без.

Ана-йортның газизлеген
Дәрман беткәч кенә аңладык.
Тик соң инде, ул туфракка
Дәфен кылына алмабыз.

Әй кардәшем, милләттәшем,
Йөрмә читтә - илеңә кайт!
Үз халкыңа хезмәтең кыйл,
Үз йортыңда азаның әйт!

# Т А Р И Х И
# Ж Ы Р Л А Р

# ФАҖИГАИ КАЗАН

Моннан дүрт йөз еллар әүвәл
нинди заманнар бар иде –
Ятка хезмәт итми идек, үз ханыбыз бар иде.
Дошман дигән бәдбәхетнең җирләре бик тар иде,
Башкаларның кенәзенә безнең татар хан иде.

Урысларның арасыннан явыз Иванай чыкты:
Кулыбыздан Казанны алып, безне аяктан екты.
Мөселманнар арасында күркәм тереклек бетте,
Бу хәбәрне ишеткәч тә Иваннар килеп җитте.

Җир астына дары куеп, кальгабызны ваттылар;
Мәсҗедләрне җимереп алып,
җир өстенә яптылар.
Оҗмах җирләр күрделәр дә гаҗәпләнеп тордылар:
«Җәннәт җирдә торган икән, кабәхәтләр!» – диделәр.

Мәсҗедләрнең башларына
кыңгыраулар тактылар,
Манарага тәре куеп, җиргә аунап карактылар,
Мөэмин-мөселман таифәсен
корбан итеп чалдылар,
Менә шунда күпме кеше мәрттә булып калдылар.

Мөселманнарны кырдылар,
хатыннарын суйдылар,
Җаек тавы итәгенә кярханәләр кордылар.
Алтын-көмеш эзләп, талап өерелеп йөрделәр,
Хәзинәгә ия булгач, тәгәрәшеп эчтеләр.

Менә шундый хәлебез, чак-чак калды җаныбыз,
Башкаларның файдасына китте безнең малыбыз.
Бетмәсләр татарлар, менә калкыр калганнар!
Әй ханымнар, калкыгыз, нигә артта калдыгыз?!

Хатын-кызны мәсҗедләргә куып кертеп,
Төннәр буе мыскыл итеп яттылар,
Таң алдыннан, толымнарын кискәннән соң,
Тәре тагып урыс иленә озаттылар.

Аналардан аерып алган сабыйларны,
Чукындырып асрау итеп алдылар.
Карт-корларга, зәгыйфьләргә рәнҗү салып,
Тере килеш кара гүргә салдылар.
Раббы әмере белән сакландылар татарлар,
Иман әһле, калкыгыз, нигә мәрттә калдыгыз?!




## ШӘҺРИ КАШАН

Кани караван вә аркушлар,
төягән нәүгы комашлар,
Панаерларда тукташлар, шәһри Болгар базарына.

Шәһәр димә боны, билкә, биләнә калдымы илгә,
Искәндәрдән мирас калды –
Биләр атлыг җиһангирга.

Шәһре Кашан җиһан гөшә,
олуг-кечек һөнәр пишә,
Алың бу мәдхе сез гүшә, биңзәер нурлуг көнәшә.

Әһле Кашан – җиһан гөшә,
　　　　　　　　　халайыкы һөнәр пишә,
Кеми сәуаг, кеми зәргәр, –
　　　　　　　　　бу сүзә кыйлмаг әндишә.

Кашан ирде бөек кальга,
　　　　　　　　　шәһри яри мөшфикъ халка,
Гадел кыйлды гидай байга, –
　　　　　　　　　боны белең колак хилка.

Базаргянләр бу көн Һиндтә,
Ярин-Хорасан, йә Кәшмирдә,
Сәяхлар күни кичләрдә,
　　　　　　　　　кунаклар дик олуг илдә.



# СӨЕМБИКӘ КИТЕП БАРА

Дүрт йөз ел буе ким-хурлыкта
Торсаң да син, әй Казан!
Сөембикә манараңда
Әйтелә бу көн азан.

Идел ага яр кагып,
Уңга-сулга чайкалып;
Ут көймәсе китеп бара
Сөембикәне алып.

Сөембикә ак яулыгын
Тоткан учлап кулына.
«Хуш, Казаным, каласың», – дип,
Үкереп елый буена.

Ия башын, түгә яшен,
Казанга таба карап:
«Миннән башка ничек итеп
Көн итәрсез», – дип аяп.






## ТОТКЫН СӨЕМБИКӘ ҖЫРУЫ

Ничә еллар бу бинада ялгыз утыра башым,
Бер савыт су, бер телем икмәк –
бәнем ашаган ашым.

Күрмәмешдер ике күзем якты дөнья йөзени,
Көне-төне еглый-еглый бетте инде күз яшем.

Хәсрәт утының сөреме каплады күзләреми,
Ут кабынган йөрәгемә, тышка да чыга аһым.

Аһ, насыйп булырмы бәңа якты дөньяны күрү?
Әллә бу зиндан эчендә чыгармы газиз җаным?

Катыйфәдәй яшел улуб тора микән җир йөзе,
Яндырып бетердеме әллә аларны да дошманым.

Бакчаларда сандугачлар сайрый микән әле дә,
Әллә аларны да тоткын итте микән дошманым?!




## СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

1 шәкел

Һәр бинадан биек улып күкләргә чыкмыш башың,
Мин беләм белдермәсәң дә: агадыр күздән яшең.

Бу хәлеңнән шикаять кылды
синең һәрбер ташың, –
Кальбеме megң парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Бер заманда синдә намаз укыганнар хан иде,
Кауме татар һәм төрекнең мәскәне Казан иде.

Ул вакытны тасвир итсәк, ни гүзәл заман иде! –
Кальбеме meң парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Һәб кәлисә уртасында ялгызың калдың ничөн?
Илтифатың без татардан син бина алдың ничөн?

Әһле ислам кальбенә син хәсрәтне салдың ничөн?
Кальбеме meң парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Бер вакытта синдә торды әһле ислам гаскәре,
Шәүкәтең бетте бүгендә, калмады меңнән бере.

Башкаларның йире булды
ошбу көн ислам йире, –
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Син өмид өзсәң дә бездән – без өмидне өзмәдек,
Заһирән түзсәк тә безләр –
кальмебездән түзмәдек.

Җаһил улган бер заманда кыйммәтеңне белмәдек,
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

2 шәкел

Әй манара, шатлан бүген –
шатлана торган көнең,
Чөнки синдә гает укый татар гаскәре бүген!

Әй манара, кайтты бүген иске шәүкәтең кире,
Тулы өметләргә чумды бүген ислам гаскәре.

Әй манара, ач пәрдәңне, кара монда бер балкып,
Дошманнарның кулларыннан
алдык сине без тартып.

Һәр бинадан биек булып
күкләргә чыкмыш башың,
Инде аеңны куябыз, күктән дә узсын башың.

Айлы манара янында Нурали дигән мәсҗед,
Ай күңелгә илһам биреп тора, галәмгә нур чәчеп.

Яшә инде, та кыямәт төшмә хурлыкка тагын,
Шатландыр халкыңны һәм дә
Хан Сөембикәнең җанын!

# ХАН МӘСҖЕДЕ

3 шәкел

Һәр бинадан биек улуб,
күкләргә чыкмыш башың.
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

Мин beләм белдермәсәң дә: агадыр,
агадыр канлы яшең.
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

Бу хәлеңнән шикаять кыйлды
синең һәрбер ташың.
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

Кальбеме мең парә кыйлды
шул гүзәл хан мәсҗеде.
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

Һәб кәлисә уртасында ялгызың калды нәчүн?
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

Илтифатың без татардан син бина алдың ничүн?
Абау Аллаһ-уф Аллаһ, татар ханнары кайда?
Татар ханнарын уйласам, була язам дивана.

# МӘХӘББӘТ ЖЫРЫ

# ХАН КЫЗЫ

– Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең буең зифа дирләр, бән күрәем.
– Бәнем буем зифалыгын сән нидәрсән?
Сазларда сары камыш күрмәймесән?!

– Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең сачең кара дирләр, бән күрәем.
– Бәнем сачем каралыгын сән нидәрсән?
Базарларда кара ефәк күрмәйсемән?!

– Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең кашың кара дирләр, бән күрәем.
– Бәнем кашым каралыгын сән нидәрсән?
Шәкертләрдә кара каләм күрмәймесән?!

Ашыкмыйча, уйнаучан



## ДӘВАЛАУ ЫРЫМЫ[†].

Җил белән кергән булса да,
урамнан кергән булса да,
Бүре угына баскан булса да,
бозыктан иңгән булса да –
Килгән урынга китсеннәр
хасталары бу бәндәнең,
Шифа килсен тәннәренә.
тынычлансын җаннары да...
Капкаларыннан чыкканда
караганнар күзеңә лә,
Башка килеп йөрмәсен дип,
көл сипкәннәр эзеңә.
Җиде юлның чатында ла,
каргаганнар үзеңне.
Яман хәбәрләр таратып,
саргайтканнар йөзеңне.
Йөзлеккә кадалган инәгә чәч кисәге уралган.
Тагын нинди кайгы керер бу бәндәгә урамнан?
Бозык ташлаган бәндәнең
йорты-җире тузгысын!
Явыз ниятле адәмнең кулы,
теле корысын...
Килгән урынга китсеннәр
хасталары бу бәндәнең,
Шифа килсен тәннәренә,
тыныч калсын җаннары да...

[†] Бозыкка юлыккан кыз баланы өшкергәндә көйләп укыла торган бозык кайтаргыч




## КЕЧКЕНӘ ДӘ ТӨШ КЕНӘ

Әлеге җыентык хакында һич арттырмыйча «кечкенә дә төш кенә» дип әйтергә ярыйдыр.

Китап белән танышып чыкканнан соң, аны төзүче, халкыбызның тыюлы заманнар шаукымыннан онытылып торган җәүһәрләрен күңелләрдә яңартып җибәрүченең үзе хакында белергә теләүчеләр дә булыр, билгеле. Зур сәхнәләрдә бу төр жанрга гомумән урын булмаган бер вакытта, аларны берәмтекләп җыеп, күңел түрендә кадерләп саклаган һәм укучыларга да җиткерергә җөрьәт итә алан кеше кем икән соң ул?

Зәйнуллин Җәмил Габделхак улы, чыгышы белән, гомерләрен халыкны укыту-агарту эшенә багышлаган мәгърифәтчеләр гаиләсен-нән. Аның әтисе Габделхак ага – үз төбәкләрендә дан тоткан Зәйнулла мулла улы, җиде буынга кадәр мәгърифәт, дин юнәлешендә халыкка хезмәт итүче муллалар, ишаннар нәселеннән булган. Әнисе Маһибәдәр ханым Хәлиулла кызы да зыялы гаиләдә тәрбия алган. Аның ата-

бабалары укымышлы кешеләр булган, сәүдә иткәннәр, матур итеп төрле-төрле уен коралларында уйнаганнар. Укымышлылык, җыр-моң сөю, музыкага һәвәслек кебек асыл сыйфатлар Маһибәдәр ханымда да нәселдән килә.

Менә шулай, борынгы мирасыбызга мәхәббәт Җәмилнең күңеленә гаиләдә үк салынган, күрәсең.

Җәмил Зәйнуллин Казан университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында гарәп филологиясе кафедрасы мөдире. Гарәп дөньясының төрле төбәкләрендә тел белгече булып эшләгән, танылган дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр, галимнәр, мәдәният һәм дин хезмәткәрләре белән якыннан аралашкан, шул илләрдә яшәгән халыкларның әдәбияты, сәнгате белән танышкан, шул ук вакытта татар мәдәниятен танытуга да өлеш керткән, вакытлы матбугат сәхифәләрендә, тамашачылар алдында да чыгышлар ясаган галим ул.

Телләр белгече, филолог-галим, педагог, фольклорчы һәм төрле жанрдагы музыкаль әсәрләрне җиренә җиткереп башкаручы... Җиде төсне җыеп алган ак төс кебек, Җәмил дә үзендә бик күп асыл сыйфатларны бергә туплаган.

Нур өстенә нур дигәндәй, халкыбызның тарихи язуын өйрәнүчеләр өчен берничә дәреслек язган һәм бу изге эшне армый-талмый бүген дә дәвам итүче автор да әле ул.

Җәмил әфәнде үзе туплаган хәзинәне халкыбызга ирештерүдә дә зур тырышлык куя. Аның «Борынгы моңнар» программасы Татарстан радио-телевидениесе аша тамашачыга аерым бер цикл буларак тәкъдим ителде.

Татар мәдәниятендә зур бер катламны тәшкил итүче бу борынгы мирасыбызны кечкенә генә бер китапка сыйдырып бетерү мөмкин түгел, әлбәттә. Китапның әһәмиятен дә, кыйммәтен дә вакыт үзе билгеләр, мөгаен. Ләкин шунысын әйтми калу ярамастыр: моңарчы татар тарихында мөнәҗәтләр, бәетләр, җыруларның бу рәвешле бергә тупланып, ноталары белән нәшриятта басылып чыкканы юк иде әле.

«Бер карлыгач яз ясамый», диләр. Әмма шушындый изге эшкә юл ячучы беренче карлыгачларның әһәмияте бәяләп бетергесез. Авторга киләчәктә дә иҗат уңышлары телик, яңадан-яңа һәм берсеннән-берсе кызыклырак хезмәтләре белән укучыларыбызны киләчәктә дә сөендерер әле ул дигән өметтә калыйк.

Марсель Бакиров,
Казан университеты профессоры.

# СҮЗЛЕК

Йә Рәсүлем!

*Сальяллаһи галәйкә* – Аллаһ сиңа рәхмәтле булсын, синнән разый булсын. *Мостафа* – сайлап алынган (Аллаһ тарафыннан). *Хәтем әннәбийә* – соңгы пәйгамбәр. *Шәфәгатьче* – яклаучы, арадашчы. *Хабибе* – сөеклесе, яратканы. *Табибе* – дәвалаучысы. *Йад итте* – искә алды, искә төшерде.

Аллаһ дию-дию

*Датлы* – татлы. *Тути* – тут агачының. *Делләре* – йөрәкләре, күңелләре, телләре. *Багының* – бакчасының. *Йийүб* – ашап, тукланып, ризаланып. *Нәби* – пәйгамбәр. *Хөллә* – кием, чапан. *Сачар* – чәчәр, таратыр. *Сөбханаллаһ* – Аллаһыга дан, рәхмәт.

Вәйселкарани

*Вәйселкарани* – Коръән кушканны үтәүче мәгънәсендә. *Гасасы* – таягы, таякчыгы. *Илкендә* – кулында. *Камәре* – билбавы, путасы. *Вар* – бар. *Зикре* – хәтер, истә тоту, искә алу. *Датлы* – татлы, тәмле. *Вәйселсолтани* – чүл хуҗасы, сакчысы. *Касды* – теләге, уе. *Хирка* – чүл гарәпләренең киеме (чапанга охшатып тегелгән).

Мәрхәбә

*Мәрхәбә* – хуш киләсең, сәлам. *Нуре гайни* – күз нуры. *Җәддүл Хөсәйни* – Хөсәеннең бабасы. *Кун шафигый* – җитәкче, яклаучы бул. *Йа хабиби* – йә сөеклем, яраткан затым. *Йәүмә хәшри вәҗтимагый* – очрашу, бергә җыелу көнендә. *Раббәна сальли галә мән* – әй Раббыбыз, һәрберебезгә шәфкатьле булсаң иде. *Хәлли фи хәйрил бәкаи* – безне мәңге үз яхшылыгыңнан ташламасаң иде. *Вә галә әлин* – барысының да, барчаның да. *Вә сахбин* – иярүчеләрнең, сәхабәләрнең дә. *Мә сагә лиллаһи* – Аллаһ тарафыннан рөхсәт ителгән изге эшләргә.

## Раббыга мәдхия

*Мәдхия* – мактау. *Хәмде* – мактау, дан җырлау, рәхмәт әйтү. *Мөэмин* – ислам динендәге кеше, хак диндәге кеше. *Йаһу* – йә Рабби мәгънәсендә. *Хыйфыз* – яклап, саклап. *Кофер-шәрик* – динсезлек, күп аллага ышанучанлык. *Мөкатдәс* – изге. *Җөмләдән ахыр* – барысыннан да соң. *Әфзаль* – иң яхшы. *Хәдисе* – сүзе. *Китабың* – «Коръән» мәгънәсен белдерә. *Иман әһле* – иманлылар, динлеләр, хак диндәге кешеләр. *Нигъмәтең* – яхшылыгың, ризыгың. *Делебездә* – йөрәгебездә, телебездә. *Дәхи фигыль гамәлебездә* – һәм эшебез, гамәлебез белән. *Нәкъсы улса да* – җитешсезлеге, кимчелеге булса да.

## Гайса көе

*Кадийр* – көчле, бар нәрсәгә дә көче җитүче; Аллаһ Тәгалә. *Йад кылдия* – искә төште. *Гизләп* – яшереп. *Мәүлем* – Раббым. *Агырлап* – олылап, хөрмәтләп. *Гыйта* – бүләк. *Хасс кол ирде мәүлегә* – Аллаһының үз колы иде. *Инҗил гыйта бирдия* – Инҗил китабын бүләк итте. *Сәүче* – гөнаһлы. *Талак бирде* – аерылды, аерды. *Кадәм орды* – аяк басты, атлады, керәште. *Гакбегә* – соңгы эшкә. *Тагат кыйлды* – буйсынды. *Уйаг* – уяу. *Әнбияләр* – пәйгамбәрләр. *Кайу әйүгә* – кайсы өйгә. *Пәнд* – киңәш. *Келим тунын* – кәфенлек. *Йимеш йитдең* – ашыйсы ашалды, яшисе яшәлде. *Тидийа* –диде, дип әйтте. *Кубдылар* – тордылар. *Йандийа* – күчтеләр.

## Укы Коръән илә намаз

*Кателгәнче* – үлемгә дучар иткәнче, җаныңны алганчы. *Әһлеңнән* – якыннарыңнан, туганнарыңнан. *Әфрак* – кәфенлек мәгънәсендә. *Хакка* – Аллаһыга.

## Касыйдәи шәрифә

*Вөҗүдем* – барлыгым яшәвем. *Җөмләсе* – барысы, бөтенесе. *Гыйсъян* – буйсынмау. *Нә хәйр, нә ихсан* – бернинди яхшылык та юк. *Гыйфран* – гафу итү. *Халаек* – кешеләр. *Заһид* – начар эшләрдән азат булган кеше, аскет. *Габид* – кол, буйсынган зат. *Суфи* – гыйбадәт, яхшы эшләр белән генә мәшгуль кеше. *Мөршид* – дөрес юл

күрсәтүче. *Гайан кыйлгай* – күрсәтә, таныта. *Зөһдин бәйан кыйлгай* – пакълеген, дөрес, туры юлдан баруын күрсәтә, таныта. *Гамәллекләр* – эше, гамәле булганнар. *Аман* – тыныч, хәвефсез. *Фазлың* – яхшылыгың, игелегең. *Кәррә гадълең* – кабат гаделлегең белән, кабатланып торган гаделлегең белән. *Ләхет* – гүр. *Ушал көн* – шул көнне. *Сәвенерсәң* – сөенерсең. *Нәгяһ* – шул чагында. *Камуг* – барча, барлык. *Йаранлары йанды* – дуслары, иптәшләре күчте.

Мөхәммәт пәйгамбәргә мәдхия
1 шәкел

*Әссаләту, вәссәләму галәйкә, йә Рәсүлүллаһ* – яхшы теләкләр сиңа ирешсен, әй аллаһының илчесе. *Хәбибаллаһ* – Аллаһының сөеклесе. *Нәбиаллаһ* – Аллаһының пәйгамбәре. *Хәйрә халикыйллаһ* – Аллаһының олуг вә яхшы заты. *Нуре гаршеллаһ* – Аллаһының күктәге тәхете нуры. *Галәйкә* - сиңа. *Сахибә кабә куатәйни* – олуг нигъмәт бирүченең (Аллаһының) бик якын дусты. *Әшрәфүл мөрсәлийнә* – җибәрелгәннәрнең (ягъни пәйгамбәрләрнең) иң бөеге, олугы. *Галә әлиһи, вә әсхабиһи әҗмәгыйн* – барлык якыннарына һәм иярченнәренә (көрәштәшләренә, дусларына). *Вәлхәмделилләһи* – һәм Аллаһыга мактау. *Раббелгаләмийн* – дөньялар хуҗасы – Раббысына. *Бирәхмәтикә* – синең шәфкатең, миһербанлылыгың, рәхмәтең белән. *Әрхамәр-рәхимийн* – иң шәфкатьле, һәм миһербанлыларның да шәфкатьлерәге, миһербанлырагы.

2 шәкел

*Шәфигаль өммәт* – өммәтенең яклаучысы, сакчысы. *Кәшифәл гоммәт* – кайгы-хәсрәттән коткаручы. *Әшрәфәл бәдрү* – иң якты, тулган ай. *Галәйна* – безгә, безнең өчен. *Фи әхтәфәт минһул будур* – һәм тулган айның нурлары сине урап алган. *Мислә хөсникә* – синең яхшылыгың, күркәмлегең кебек (сыйфатларны). *Мә рәэйнә катту* – әле күргәнебез юк иде, беркайчан да күрмәдек. *Вәҗәһәс сорур* – шат йөз, шатлыклы, ачык, якты йөз (чырай). *Әнтә бәдрүн* – тулган ай син. *Иксийр* – 1. Шифалы тамчы. 2. Эликсир. *Галийүн* – бөек, олуг. *Мисбах* – яктылык чыганагы, яктырткыч. *Содур* – күңелләр (күкрәкләр). *Хабиби* – сөекле, яраткан. *Горвасәл хафикайн* – көнбатышның да, көнчыгышның да гөле. *Муәййәд* – ярдәм итүче, хәлне аңлаучы. *Мумәҗҗәд* – иң олы,

иң бөек зат, мәңгелек данга лаек зат. *Имаму кыйблатәйн* – ике кыйбланың да имамы, ягъни Мәккәнең һәм Әл Кодеснең (Иерусалимның да). *Фи мәганикәл әнгаму кад тәбәддәт хайрийнә* – синең бөек, олуг, күркәм сыйфатларың адашкан, югалып калган, кыенлыкка очраганнар өчен туры юл булып тора. *Лиррусүли хитамүн* – илчеләрнең (пәйгамбәрләрнең) соңгысы. *Лил-мәулә шәкүрүн* – иң зыялыларның да иң рәхмәтлесе. *Габдүкәл мискину* – синең мескен колың. *Йәрҗү* – ялвара, сорый, үтенә. *Фазләкәл җәмал* – синең күркәм, матур сыйфатың, игелегең... *Гафиру*- кичерүче, гафу итүче.

## Хәзрәтләр мөнәҗәте

*Сөннәт* – тиешле. *Аһ дәрига* – ни үкенеч. *Хублары* – яхшылары, олы затлары, зыялылары. Тугды исә – тугач ук, тууы белән. *Матәм тотты* – кайгы тотты. *Сабыр-җәмил* – күркәм сабырлык. *Гыйшрәт* – кәефләнде, ләззәт тапты. *Нух Нәби* – Нух пәйгамбәр. *Фәүзе-нәҗат кыйлгыл* – коткар, саклап кал.ярдәм бир. *Юныс нәби* – Юныс пәйгамбәр. *Эчрә* – эчендә. *Истикамәт* – тугрылык, дөреслек; намуслылык. *Ягъкуб нәби* – Якуб пәйгамбәр. *Сыйддикъ* – турылыклы, дөрес юлдан баручы. *Фәхре* – горурлыгы, иң олысы, даны. *Йәзид кауме* – Гали хәзрәт үлгәннән соң гарәп халифатында хәкимияткә килүчеләр (Йәзидиләр). *Кәрбәлә* – Гыйрактагы шәһәр исеме. Бу шәһәрдә Гали хәзрәтнең Хөсәен һәм Габбас исемле уллары күмелгән. Алар Сүрия хакиме Йәзид ибне Мугавий тарафыннан үтерелгәннәр дип фараз ителә. *Чаһар йарлар* – дүрт иярчен (Мөхәммәт пәйгамбәрнең дуслары, көрәштәшләре, дәвамчылары – Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали).

## Әҗәлләргә дәвалар юк...

*Дидарыңны* – йөзеңне. *Бакый* – мәңгелек. *Кәүсәр* – җәннәттәге елга исеме. *Фирдәвеси җәннәт* – җәннәт бакчасы.

## Әлвидаг

*Әлвидаг* – саубуллашу, озату. *Шәһри рәхмәт* – рәхмәт, шәфкать ае. *Мәләик* – фәрештәләр. *Чуглашырлар* – сайрашырлар. *Зәйн улыб* – матурланып, бизәлеп. *Җөмлә мәсҗедләр* – барлык мәчетләр. *Вә*

*тәравих* – Рамазан аенда һәркич укыла торган егерме рәкәгать намаз. *Зикре тәсбих* – Аллаһы тәгаләне кимчелекләрдән пакъләп искә алу. *Аять-аять бәйинат* – өлеш-өлеш, ачык һә аңлаешлы аятьләр булып. *Хасәнәтләр* – яхшылыклар, күркәмлекләр. *Тәшриф* – олылау, зурлау. *Сәйедат* – олуглык, бөеклек. *Җөмләдерлү* – барысы да, барысы бергә. *Нурдин табак* – нур шикелле, нурга охшаш. *Сонарлар* – сакларлар. *Гофран* – гафу итү, кичерү. *Мөхәммәт өммәтирсәң* – Мөхәммәт динендәсең. *Ихсан* – яхшылык, миһербанлылык.

## Алты бармак

*Пәс* – соңыннан, азактан. *Нә истәрсәң* – нәрсә теләсәң. *Уийрам хаҗәт рәүа* – нәфеснең яман икәнлеген ачык бел мәгънәсендә. *Рәфыг улды хиҗаб* – пәрдәне күтәрде, ачты. *Нуре кодәс* – изге, мөбәрак нур. *Сачылды* – чәчелде. *Канәдин орды* – канаты белән кагылды, сукты. *Күркесе* – матурлыгы. *Әтайиб* – иң яхшы. *Сөйләдеке* – сөйләгәне, әйткәне. *Хөлләләр* – матур киемнәр, чапаннар.

## Ахирәт көне

*Һиммәте* – бөек уй-теләк, ният. *Шәфәгать кыйлсын* – җитәкләсен, җитәкче булсын. *Хабибем* – сөеклем, яратканым. *Мәлгунь* – ләгънәт укылган, каргалган. *Мөнкир, Нәкир* – үлем фәрештәләренең исемнәре.

## Аһ дәрига

*Дәрига* – ни үкенеч, ни аяныч. *Һәрнә* - барысы да, бөтенесе дә, һәрнәрсә. *Хасыйл* – бар булу, барлыкка килү. *Дәгъвалы* – гаепле, ярамас, бәхәсле. *Милкем* – байлыгым. *Залим* – җәберләүче, шәфкатьсез кеше. *Гыйш-гыйшрәт* – ашап-эчеп, кәефләнеп вакыт уздыру. *Вафа кыйлмас* – сүзендә тормас, ярдәм итмәс. *Гакыл ирсәң* – акыллы булсаң, акылың булса. *Мәүте каблә* – үлмәстән борын, үлгәнчегә кадәр. *Сари* – ияреп йөрү, кушканча эшләү. *Тагатларын* – буйсынуларын. *Пинһан кыйлур* – яшерер. *Кәси* – кеше, кемдер, кем дә булса. *Тагат кыйлгыл* – буйсын, тыңла. *Рия* – кылану, икейөзле булу. Гыйсъян карышу, буйсынмау, баш тарту.

## Кыйссаи Авык

*Юл үзрә* – юл буенда, юл янында. *Авык* – чүлдә яши торган газәл (кәҗәләр токымыннан). *Кяфир* – ислам динендә булмаган кеше. *Сәвеклүк* – сөекле. *Разын әйтүр* – теләген әйтер, белдерер. *Җадуа* – күрәзә, сихер. *Җадуалыклар* – күрәзәчелек, сихерчелек. *Кателләнүрсән* – өзгәләнәсең, бар көчеңә тырышасың. *Өнүн* – тавышын, авазын. *Кечүчүк угланнары* – кечкенә уллары, балалары. *Баек* – ачык. *Эйүнә* – өенә. *Кайра килсен* – кире борылып килсен, кайтып килсен. *Фасыйх делен* – матур телен. *Мәңзен* – йөзен. *Күксүмдәге* – күкрәгемдәге. *Илкүмүздән* – кулыбыздан. *Кәндү* – үзе. *Разын* – теләген. *Кубубән* – торып, кубып. *Имүң* – имегез. *Нитәк* – ничек итеп. *Икеләсе* – икесе. *Калуң* – калыгыз. *Кузыларым* – балаларым, бәтиләрем. *Шәфәгать итү* – җитәкче булу, яклаучы булу. *Икселмәз* – киселмәс, өзелмәс. *Әйгел* – әйт әле. *Илән* – белән. *Хадыр булды* – әзер булды. *Дәкүл* – түгел. *Тийүр* – дияр. *Тагга* – тауга. *Буйуңны йөккә* – үзеңне аның урынына куй. *Килмәз ирсә* – килмәгән очракта, әгәр килмәсә. *Баек беләм* – ачык беләм. *Катигъ хаҗәт кыйлур* – катгый итеп таләп куйды. *Күзен тикүб* – күз нурын түгеп, күзен арытып. *Бакуб* – карап. *Кайра бакуб* – кире карап, яңадан әйләнеп карап. *Ушал ийшә* – шул рәвештә. *Атдаен* – аттан төшү (югарыдан төшү). *Без тик* – безнең кебек, бездәй. *Йөзен орды* – башын иде, ишарәләде. *Ике пучук* (яки бучук) – ике буй үлчәмендә. *Түкәл* – юан, симез, үз-үзеннән канәгать мәгънәсендә. *Шам халкы* – Сүрия халкы. *Шәһадәтне килтерүр* – таныклык китерер, таныр.

## Бәйте Шәһри Казан

*Бөлекнең* – буйсындырылуның, басып алуның. *Кәлүбән* – килеп. *Газилары* – олы, асыл затлары, зыялылары. *Кямилләре чук иде* – булдыклы, зыялы, укымышлы кешеләре күп иде. *Җиһан* – дөнья, илкөн. *Мөнәүвәр* – яктыртылган, яктылыклы; гыйлемле затлары күп иде мәгънәсендә. *Җәүер-җәфа* – җәбер-җәфа. *Мөрид-мөршид* – дөреслеккә, тугрылыкка, яхшылыкка өндәүчеләр, юл күрсәтеп баручылар. *Хуб* – яхшы. *Пәст* – түбән дәрәҗәле, надан, караңгы. *Мүәннәс дәгүлмүсән* – хатын-кыз җенесендә түгелме син. *Монча* – бу кадәр. *Халаек* – кешеләр, халык. *Вәли* – хуҗа, асыл зат. *Шәһадәтдәр тапдыя* – шәһит булдылар, үтерелделәр. *Бихәбәр* – белмиләр, белми иде. *Орыш-тукыш* – сугыш-кырыш. *Кандин кәлдең* – кайдан килдең. *Кәлибсән* – син килдең. *Мәкам*

*кылыбсән* – урнаштың, килеп утырдың, җиргә хуҗа булдың. *Диюбән* – дип. *Җиһад* – сугыш. *Мәрди хода* – ходаның ир-ат җенесендәге бәндәсе, ир-егет. *Мәдад* – ярдәм. *Кәлгүнчә кемсә күрмәс* – килеп җиткәнче һичкем күрмәде. *Тиделәр аңа* – аңа әйттеләр. *Чадырда* – чатырда. *Кәтгүнчә* – киткәнче. *Уструг* – биредә «үрә катып басып тор» мәгънәсендә булса кирәк. *Гакрәб* – чаян (ай исеме).

## Фаҗигаи Казан

*Таифәсен* – төркемен, халкын. *Кярханәләр* – тән белән сату итеп көн күрү йортлары.

## Шәһри Кашан

*Аркушлар* – кәрван әйдәүчеләр. *Нәүгы* – төрле, сортлы. *Комашлар* – тукымалар. *Панаерлар* – ярминкәләр. *Билкә* – хаким. *Атлыг* – исемле. *Җиһан гөшә* – дөньяның чагылышы, көзгесе мәгънәсендә. *Олуг-кечек* – олысы-кечесе. *Һөнәр пишә* – һөнәрле, һөнәр иясе. *Мәдхе* – мактау. *Гүшә* – колака. *Биңзәер нурлы көнәшә* – кояш нурына охшар. *Кеми сәуаг* – кайсы корыч эретүче. *Зәргәр* – алтын-көмештән бизәнү әйберләре ясаучы, ювелир. *Әндишә* – (кыйлма әндишә) шикләнмә. *Кальга* – кала, ныгытма, крепость. *Мөшфикъ халка* – игелекле, шәфкатьле халкы. Гидай – ярлы, фәкыйрь, мескен. Хилка – түгәрәк алка таккан, алкалы (кол мәгънәсендә). *Базиргән яки базаргян* – сәүдәгәр. *Ярин* – иртәгә, иртәгесе көндә. *Сәяхлар* – сәяхәтчеләр, килүчеләр.

## Тоткын Сөембикә җыруы

*Катыйфәдәй* – хәтфәдәй. *Улуб* – булып.

Сөембикә манарасы
1 шәкел

*Шикаять кылды* – зарланды, әрнеде. *Кальбеме* – күңелемне, йөрәгемне. *Мәскәне* – торган, яшәгән урыны, җире. *Һәб (һәп) кәлисә* - гел чиркәүләр. *Әһле ислам* – ислам динендәге халык. *Шәүкәт* – көч-куәт, бөеклек. *Йире* – җире. *Заһирән түзсәк тә безләр* - тыштан гына түзсәк тә, түзгән сыман булып күренсәк тә. *Кальмебездән* – күңелебез, йөрәгебез белән. *Җаһил улган бер заманда* – караңгылыкка чумган бер вакытта, заманда; наданлык сөреме белән капланган бер чорда.

2 шәкел

*Шәүкәтең* – бөеклегең. *Та кыямәт* – кыямәткә кадәр.

Хан кызы

*Нидәрсән* – нәрсә өчен. Күрсәң нишләрсең, нигә күрергә мәгънәсендә.

## АҢЛАТМА ҺӘМ ИСКӘРМӘЛӘР

«Вәйселкарани» – Төрки халыклар арасында, шул исәптән татарларда да, киң таралган әсәр.

«Мәрхәбә» – Мөхәммәт пәйгамбәрнең туган аенда күмәкләп башкарыла торган әсәр. «Салават әйтү»нең бер шәкеле.

«Әлвидаг» – Рамазан аенда күмәкләп башкарыла торган әсәр. Бу әсәрнең көйләп башкарылышы төрле төбәкләрдә төрлечә. Җыентыкта аның Иске Кади авылындагы шәкеле бирелде.

«Касыйдаи шәрифә» – Ш. Суфыйның бу әсәре Николай Чернышевский кульязмасыннан күчереп алынды (ЦГАЛИ, Мәскәү, фонд -1).

«Укы, Коръән илә намаз» – Безгә бу әсәрнең ике төрле көе мәгълүм. Җыентыкта бер генә шәкеле тәкъдим ителә.

«Алты бармак» – Әсәрнең тексты Н.Г. Чернышевский кульязмасыннан күчерелде. Көе Чирмешән районы Иске Кади авылында Г. Зәйнуллиннан язып алынды.

«Себер киткән егет» яки «Каторжан бәете» – Үзбәкстанның Кукан шәһәрендә яшәүче пенсиядәге укытучы М. Зәйнуллиннан язып алынды. Мөхәммәт ага Зәйнуллин Татарстанда туып үскән (1898–1970). Заманының танылган мәдрәсәләрендә (Кизләү, Мөхәммәдия) һәм «Учительская школа»да (Чистайда) белем алган. Сәнәкчеләр фетнәсе вакытында һәм соңыннан кызыллар тарафыннан җәзалауларга дучар ителгән. Урта Азиядә мөгаллимлек иткән, җаваплы эшләрдә эшләгән. Төрки кардәшләребезне мәгърифәтле итүгә зур хезмәт куйган, гомере буена татар мәдәниятен, сәнгатен, әдәбиятын төрки халыклар арасында танытуга, пропагандалауга тырышып хезмәт иткән Мөхәммәт ага Кукан шәһәрендә 1970 елда вафат булды. Хатыны һәм улы да фаҗигале рәвештә шунда һәлак булалар.

«Фаҗигаи Казан» – Көе дә, тексты да Иске Кади авылында Габдрахман ага Вәлиуллиннан язып алынды. Әсәрнең «Ханумнар, калкыгыз!» исемле шәкеле дә бар. Бу турыда фольклорчы-галим Риф Мөхәммәтҗанов «Шәһри Казан» газетасында бастырып чыгарган иде. Әсәрнең соңгы ике куплеты еглау-сыктау төсмере белән башкарыла.

«Сөембикә манарасы» – 1918 елда татарлар арасында яратып җырланган. Аның көе халыкныкы. Бу бәетнең берничә шәкеле бар. Җыентыкка өч шәкеле кертелде. М. Гафури халык сүзләренә таянып, үз шәкелен иҗат иткән.

«Сөембикә китеп бара» – Әсәрнең көе фин җирендә яшәүче милләттәшләребездән язып алынды. Тәфсиллерәк мәгълүматны «Татар халык иҗаты» мәҗмүгасенең «Тарихи һәм лирик җырлар» китабыннан табарга мөмкин (Казан, 1988, 39 б.).

«Тоткын Сөембикә җыруы» – Финляндиядәге татарлар аны безгә мәгълүм «Тәфтиләү» көенә күмәкләп башкаралар. Текстын «Тарихи һәм лирик җырлар» китабыннан карагыз (Казан, 1988, 40 б.).

«Хан кызы» – Бу җырның көен Чирмешән районы Яңа Кади авылында Суфиян бабайдан язып алдык. «Хан кызы» турындагы тулырак мәгълүматны «Тарихи һәм лирик җырлар» китабыннан карагыз (Казан, 1988, 216 б.).

«Шәһри Кашан» текстны башлап өйрәнүче һәм гамәлгә кертүче – галим Марсель Бакиров. Әсәр бик сузынкы итеп, мәкамгә якынайтып көйләнелә. Көйгә салып беренче тапкыр басыла.

«Бәйте Шәһри Казан» – Бу әсәрнең тексты Каюм Насыйриның «Моңарчы басылмаган әсәрләр» исемле китабыннан алынды (Казан, 1926). Көйгә салып беренче тапкыр бирелә.

«Үги бала бәете» – Шигырьнең исеме юк, бередә ул шартлы рәвештә «Үги бала көе» исеме белән бирелде. Авторы – гомерен фин җирендә уздырган, ләкин туган илен, туган җирен сагынып яшәгән Хәсән Хәмидулла. Текстны Хельсинкида яшәүче Фазыйлә ханым Насретдин архивында саклана торган Хәсән Хәмидулланың шигырь тупламасыннан күчереп алдык.

Шигырьнең бу көй белән башкарылышын Хельсинкида яшәүче милләттәшебез Нурмөхәммәт ага Самәрханнан ишеттек.

«Тәравих тәсбихе»нең көен әтиебез Габделхак Зәйнуллиннан отып алган идек.

«Дәвалау ырымы» – Бу йола салмак кына башлана, соңгарак тизләтелгән темпта, төрле авазлар белән тулыландырып башкарыла. Иске Кади авылында Фатыйма әби Шәриповадан язып алынды.

«Татар мөһаҗире бәете» – Бу бәетне Ташкент шәһәрендә Заһретдин бабайдан күчереп алган идек. Ә ул аны Казагыстанның Шымкент (Чимкент) шәһәрендә тапкан булган. Берничә куплетын Ташкентта яшәүче галим Мидхәт ага Булатовтан язып алдык.

«Кыйссаи Авык» – Н.Г. Чернышевский кулъязмасыннан күчереп алынды. Галимнәр фикеренчә, бу әсәр 14–15 йөзләрдә иҗат ителгән (Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 1 том. Казан, 1984, 119 б.).

«Салават әйтү» – халык арасында төрлечә башкарыла: салмак кына көй белән, укыган сымак яки билгеле бер борынгырак халык көенә дә әйтелә. Мәскәү шәһәрендә безгә «Салават әйтү»нең Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре көенә башкарылуын ишетергә дә туры килде. Аны Гөлмиҗамал апа Ризванова башкарган иде.

**Габделҗәмил Габделхак улы Зәйнуллин**

# *Мөнәҗәтләр, бәетләр һәм тарихи җырлар*

***Корректоры – Г.Т. Гыйләҗева***
***Тышлык бизәлеше – М.А. Әхмәтов***
***Компьютерда җыю – Р.М. Абдрахманова***

Басарга кул куелды 08.10.2014.
Офсет кәгазе. Цифрлы бастыру.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Шартлы басма табагы 3,5. Шартлы нәшр. табагы 1,37.
Тираж 85. Заказ 159/6.

Казан университеты нәшрияты

420008, Казан, Проф. Нужин ур., 1/37
Тел. (843) 233-73-59, 233-73-28